ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР № 25

Бәйрәкәтамак ав. 20.09.2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2017 елның 13 мартындагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башкарма комитеты нигезләмәсен раслау турында»гы 4 санлы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Үз көчен югалткан дип түбәндәгеләрне танырга:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2017 елның 13 мартындагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башкарма комитеты турында»гы 4 санлы карарын;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2018 елның 1 июнендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»гы 12 санлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Бәйрәкәтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы урынбасары Ф.Г.Локманов